| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |


| | |
|---|---|
| 422051, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Корсабаш, ул. Школьная, д. 28 тел. (84362) 2-27-49 | 422051, Татарстан Республикасы, Саба районы, Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт тел. (84362) 2-27-49 |

e-mail: korsab.sab@tatar.ru


| | |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>19.12.2023 | КАРАР<br>№30 |

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 08.11.2021 ел, №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турындагы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советы Карар итә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел, №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба – положение тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны яна редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 30 нчы номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында 2нче Нигезләмә

Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.